Министерство цифрового развития
государственного управления, информационных
технологий и связи Республики Татарстан

ГОД ЦИФРОВИЗАЦИИ
В РЕСПУБЛИКЕ
ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ЦИФРЛАШТЫРУ ЕЛЫ

ДАННЫЕ
НОВАЯ НЕФТЬ

*СВЯЗЬ – РЕЛЬСЫ ЦИФРОВОЙ ЭКОНОМИКИ*

# ТРАНСФОРМИРУЕМ НАСТОЯЩЕЕ

## ИТОГИ РАБОТЫ ЗА 2022 И ПЛАНЫ НА 2023

*ВРЕМЯ – САМЫЙ ЦЕННЫЙ РЕСУРС ЧЕЛОВЕКА*

ДАТА
ЦЕНТРИЧНОСТЬ

КЛИЕНТО
*ЦЕНТРИЧНОСТЬ*

*ЦИФРОВАЯ ЗРЕЛОСТЬ*

# ОГЛАВЛЕНИЕ


## Тармак икътисады – 8

Тармак кереме

Барлык дәрәҗәләр бюджетына салым түләүләре

Тармак оешмаларының саны арту

Айлык уртача хезмәт хакы

Төбәк проектлары

«Цифрлы Татарстан» дәүләт программасы

IT-өлкәгә ярдәм чаралары

«Иннополис» махсус икътисад зонасы

## Цифрлы икътисад кадрлары – 20

Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясендә белем алу

Stepik онлайн белем бирү платформасында укыту

«Цифр дәресе» белем бирү проекты

«Цифрлы һөнәрләр» дәүләт программасы

«Киләчәк коды» проекты

Яндекс Академиясе Лицее

Мәктәп 21 (Школа 21)

ИТ өлкәсендәге белгечлекләргә өйрәтү буенча югары һәм урта һөнәри белем бирү йортлары

КФУ Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институтының иң яхшы студентларына грантлар

DigitalSkills

«Кванториум» балалар технопаркы

«Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» ДАҺБУ

IT-CUBE

## Телекоммуникация һәм элемтә – 36

Мобиль элемтә

УЦН 2.0 проекты

GPON технологиясе буенча челтәрләр төзү

Мәктәпләрнең ИТ-инфраструктурасы

Бюджет учреждениеләрен һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарын интернет челтәренә тоташтыру

Почта элемтәсе

«Чиста күк йөзе» проекты

Куркынычсыз шәһәр

## Мәгълүмати куркынычсызлык – 48

«Мәгълүмати куркынычсызлык» төбәк проекты

Татарстан Республикасы кибер-куркынычларны булдырмый калу үзәге

## Импортны алмаштыру – 52

Аппарат белән тәэмин өлкәсендә импортны алмаштыру

Программа тәэминаты буенча импортны алмаштыру

## Цифрлы трансформация үзәге – 56

Электрон документ әйләнеше

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы

Татарстан Республикасы рәсми порталы

Үзәкләштерелгән бухгалтерия

ТР пространство мәгълүматларының төбәк порталы (Геопортал РТ)

Белешмәләр фабрикасы

Кире элемтә платформасы

Халык контроле

Халык инспекторы

ТР яшәүчеләрне сораштырулар

Минем субсидияләр

Мин төзим

## Мәгълүмат технологияләре үзәге – 76

Бердәм цифрлы платформа

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү» гамәли платформасы

Видеоконференцияләр оештыру өчен iZUM платформасы

## Күпфункцияле үзәкләр – 82

## Тармакларны цифрлаштыру – 86

Цифрлы мәгариф

Мин – мәктәп укучысы

СФЕРУМ

«Электрон балалар бакчасы» системасы

Төзелешне цифрлаштыру

«ТР шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү» мәгълүмат системасы

Социаль өлкәне цифрлаштыру

Кайгырту

Экологияне цифрлаштыру

Сәламәтлек саклауны цифрлаштыру

Транспорт өлкәсен цифрлаштыру

Икътисад тармагын цифрлаштыру

Цифрлы юстиция

Цифрлы авыл хуҗалыгы

Цифрлы урман хуҗалыгы

Цифрлы ветеринария

Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсен цифрлаштыру

«Каскад» муниципаль мөлкәт белән идарә итү системасы

Яшьләр өлкәсен цифрлаштыру

Спортны цифрлаштыру

Мәдәниятне цифрлаштыру

Туристлыкны цифрлаштыру

Биологик ресурслар тармагын цифрлаштыру

Архив эшчәнлеген цифрлаштыру

ТКХ цифрлаштыру

ЛОКОЛО

ГТХМ цифрлаштыру

Сатып алулар өлкәсен цифрлаштыру

ТР ИҮА цифрлаштыру

Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсен цифрлаштыру

Сәнәгатьне цифрлаштыру

Тарифлар өлкәсен цифрлаштыру

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр тармагын цифрлаштыру («Татмедиа»)

## 2022 Цифрлаштыру елы чаралары – 124

## Югары технологияләр өлкәсендә «ИТ-Парк» технопаркы – 134

Б.Рәмиев исемендәге IT-парк һәм мультиплатформа

Казан ИТ-паркының беренче мәйданчыгы

Казан ИТ-паркының икенче мәйданчыгы, Чаллы шәһәре

# ВЛАДИМИР ПУТИН

Россия Федерациясе Президенты



Безгә цифрлы үзгәртеп кору тизлекләрен һәм аерым тәҗрибәләрдә булган тизлекләрне һәр җирдә арттырырга, мөмкин кадәр кыска чорларда ясалма интеллект өлкәсендә уңәли проектларны эшләтеп җибәрүгә күчәргә кирәк... Киләчәк технологияләре илнең барлык гражданнарына хезмәт итсен, безнең илкүләм үсеш максатларына ирешсен өчен эшләрлек итәргә кирәк. Дәүләтнең, инженерларның, галимнәрнең һәм инновация бизнесеның үзмаксаты нәкъ менә шуннан гыйбарәт



Мин чын күңелдән ышанам, технологияләр XX гасыр дәвамында тормыш сыйфатын ничек итеп шактый күтәргән булсалар, үсешнең хәзерге дәвере дә, цифрлаштыру, сәнәгатьтә барган үзгәртеп корулар биргән мөмкинлекләр дә безнең өчен файда китерәчәк

## МИХАИЛ МИШУСТИН

Россия Федерациясе
Рәисе Хөкүмәте



Цифрлаштыру үзмаксат түгел. Бу, беренче чиратта, гражданнарыбызның тормыш сыйфатын күтәрергә, аларның тормыш дәрәҗәсен һәм керемнәрен, шулай ук бизнесның конкуренциягә сәләтлелеген тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган чара. Алга таба «цифр»га күчү өчен, безгә принципиаль нигездә яңа дәрәҗәдәге авыр мәсьәләләргә алынырга туры киләчәк

# РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ

Татарстан Республикасы Президенты



01



## ИТ ПРОДУКТЛАРЫН САТУДАН ТАРМАК КЕРЕМЕ
**млрд.сум**




Базар чикләүләренә карамастан, тармак керемнәренең фаразланган үсеше дәвам итә. IT-технологияләргә булган бәйлелек арта бара, ә тормыш һәм бизнесны цифрлаштыру күрсәтелә торган хезмәтләр үсешенә һәм яңа җиһазлар сатып алуга, искергәнне заманчалаштыруга ихтыяҗ тудыра. Базар үзебезнең программа продуктларына һәм җиһазларына йөзү тоту өчен үзгәрә, параллель рәвештә Азия төбәге илләреннән кертүнең логистика чылбырлары корыла.

## БАРЛЫК ДӘРӘҖӘ БЮДЖЕТЛАРЫНА САЛЫМ ТҮЛӘҮЛӘРЕ




Барлык дәрәҗә бюджетларга түләүләр күләме сизелерлек артты. Гомуми үсеш күләменең 63 процентында төп үсеш өстәмә хак салымының артуына китерде, бу исә Россия кулланучысына IT продукциясен җибәрү күләменең дә артуын күрсәтә.

## ТАРМАК ОЕШМАЛАРЫНЫҢ САНЫ АРТУ




Елның үзенчәлекле килүе дөньядагы чит ил корпорацияләренең китүенә бәйле рәвештә тармак оешмалары структурасында сыйфатлы үзгәрешләр китереп чыгарды. Игътибар Россия чишелешләренә юнәлтелде, төбәк компанияләренең компетенцияләре артты һәм РФ Хөкүмәте тарафыннан тармакка моңарчы күрелмәгән ярдәм шартларында яңа ИТ-стартаплар саны артты.



## КЕЧЕ ЭШКУАРЛЫК СУБЪЕКТЛАРЫН ДА КЕРТЕП, УРТАЧА АЙЛЫК ХЕЗМӘТ ХАКЫ




ТР буенча уртача айлык хезмәт хакы

Мәгълүмат һәм элемтә өлкәсендә икътисад эшчәнлегенең төре буенча уртача айлык хезмәт хакы

**12%**

Ел башына уртача хезмәт хакы 12 процентка артты.

Зур эш тәҗрибәсе һәм киң компетенцияләре булган белгечләргә ихтыяҗ артты. Бигрәк тә программа тәэминатын эшләү, мәгълүматны анализлау өлкәсендә яңа компетенцияләр, виртуаль һәм 3D чишелешләр эшләү белән бәйле.

## ТӨБӘК ПРОЕКТЛАРЫ

**5**
төбәк проекты

**235,5**
**млн.сум**
2022 елга ассигнованиеләр күләме 235,5 млн.сум

**146,3**
**млн.сум**
шул исәптән 146,3 млн.сум – федераль акчалар.

| | Финанслау чикләре мең сум | Күренеш 2022 ел |
|---|---|---|
| Мәгълүмат инфраструктурасы | 180 666,4 | 0 % |
| Цифрлы икътисад өчен кадрлар | 22 684 | 99,73 % |
| Мәгълүмати куркынычсызлык | 600 | 100 % |
| Цифрлы технологияләр | 6 523,8 | 100 % |
| Цифрлы дәүләт идарәсе | 25 000 | 100 % |

## «ЦИФРЛЫ ТАТАРСТАН» ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАСЫН ФИНАНСЛАУ

**42**
чара

**100**
күрсәткеч

**3,4**
**млрд.сум**
2022 елга ассигнованиеләр күләме

**0,145**
**млрд.сум**
шул исәптән федераль акчалар

## «ЦИФРЛЫ ТАТАРСТАН» ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАСЫН ФИНАНСЛАУ




# ИТ-ӨЛКӘГӘ ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә мәгълүмат технологияләре тармагының тизләтелгән үсешен тәэмин итү чаралары турында» 2022 елның 2 мартындагы 83 номерлы указы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары нигезендә профильле компанияләр өчен зур салым ташламалары булдырылды.

**831**
аккредитацияләнгән ТР оешмасы федераль реестрына кертелгән

**335**
аккредитацияләнгән ТР оешмасы түбәнәйтелгән иминият кертемнәреннән файдаланган

Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматлары буенча, табышка салым буенча түбәнәйтелгән ставкаларны аккредитацияләнгән 51 ИТ-предприятие кулланган, бу 2021 ел дәрәҗәсеннән 41 процентка артыграк.

Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе мәгълүматлары буенча, табышка салым буенча түбәнәйтелгән ставкаларны Татарстан Республикасының аккредитацияләнгән 335 ИТ-оешмасы (7,6%) кулланган, бу күрсәткеч 2021 ел дәрәҗәсеннән 37% күбрәк.

## Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча табышка түбәнәйтелгән салым ставкаларын кулланган Татарстан Республикасы ИТ-предприятиеләре өлеше




2021




2022

- 62.01 «Компьютер программалары эшләү»
- 63.11.1 «Белешмәләр базаларын һәм мәгълүмат ресурсларын булдыру һәм файдалану эшчәнлеге»
- 62.09 «Санап чыгару техникасын һәм мәгълүмат технологияләрен куллануга бәйле эшчәнлек, башка»
- 62.0 «Компьютерга программа тәэминаты эшләү, бу өлкәдә консультация хезмәтләре һәм аңа бәйле башка хезмәтләр»
- 62.02 «Консультатив эшчәнлек һәм компьютер технологияләре өлкәсендәге эшләр»

## Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча түбәнәйтелгән иминият кертемнәре ставкаларыннан файдаланган ТР ИТ-предприятиеләре өлеше




2021




2022

- 62.01 «Компьютер программалары эшләү
- 62.02 «Консультатив эшчәнлек һәм компьютер технологияләре өлкәсендәге эшләр»
- 62.03 «Компьютер җиһазлары белән идарә итү эшчәнлеге»
- 62.09 «Санап чыгару техникасын һәм мәгълүмат технологияләрен куллануга бәйле эшчәнлек, башка»
- 63.11 «Белешмәләрне эшкәртү эшчәнлеге, мәгълүмат урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтү һәм шуңа бәйле эшчәнлек»
- 63.12 «Web-порталлар эшчәнлеге»
- 62.0 «Компьютерга программа тәэминаты эшләү, бу өлкәдә консультация хезмәтләре һәм аңа бәйле башка хезмәтләр»




## 330 кеше

Татарстаннан хәрби хезмәткә чакырылган 330 кеше – ИТ-корпорацияләр хезмәткәрләре Дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталы аша армиядә хезмәт итүдән кичектерү буенча РФ Цифр министрлыгына гариза бирделәр һәм дәүләтнең әлеге ярдәм чарасыннан файдаландылар



**1 066**
Республиканың ИТ-белгечләре тарафыннан ташламалы ипотека кредитларын алу өчен бирелгән гаризалар саны

**220**
ипотека кредиты буенча төзелгән шартнамәләр саны

**1,9 млрд.сум**
ипотека кредиты буенча шартнамәләр суммасы

**ДОМ.РФ**
программа операторы

## Ташламалы ипотека алу шартлары:

- 22 яшьтән 45 яшькә кадәр булу
- хезмәт хакы аена 150 мең сумнан башлана
- Россия гражданлыгына ия булу
- аккредитация узган ИТ-компаниядә эшләү
- миллионлы шәһәрләр өчен кредит суммасы – 18 млн.сум
- иң зур ставка – 5%
- беренче түләү – кимендә 15%
- яңа төзелештәге фатир/йорт сатып алу һәм төзү/җир кишәрлеге сатып алу өчен.

**Федераль ярдәм шартларыннан тыш, Татарстан гадиләштерелгән салым салу ставкаларын киметү буенча үзенең «кІТык» программасын тәкъдим итә.**

Программа кысаларында гадиләштерелгән салым салу ставкалары кертелде: “Керем” статьясы буенча 1% һәм “Керем минус чыгым” статьясы буенча 5%.

**327**

Татарстан предприятиесе гадиләштерелгән салым салу ставкаларын киметү буенча үзенең кІТык программасын кулланган






# «ИННОПОЛИС» МАХСУС ИКЪТИСАД ЗОНАСЫ

Иннополис үсешенең уңай динамикасын дәвам иттерде. Яңа инвестицияләрне җәлеп итү әйләнешләрен арттырды, яңа резидентлар исемлеген зурайтты. Безнең ил өчен технологияләрне үстерү һәм импортка бәйсезлекне һәм кадрлар белән тәэмин итү буенча төп терәк ноктасына

## нәтиҗәләр

**68**
резидент, партнер, стартап җәлеп ителгән

**5 268**
эш урыны булдырылган

**2025 елга кадәр халык санын 15 000 кадәр арттыру планлаштырыла**

**14,9 млрд.сум**
инвестицияләр күләме

**38,3 млрд.сум**
табыш (2022 фаразы)

**5,7 млрд.сум***
түләнгән салымнар (2022 фаразы)

** барлык дәрәҗә бюджетларга түләнгән салымнар һәм җыемнар күләме

# ЦИФРЛЫ ИКЪТИСАД КАДРЛАРЫ



# ЦИФРЛЫ ИКЪТИСАД КАДРЛАРЫ

Компетентлы командалар һәм квалификацияле хезмәткәрләр цифрлы икътисад өлкәсендәге төп бурычларны хәл итү өчен нигез булып тора.

## ОБУЧЕНИЕ В РАНХИГС

### НӘТИҖӘЛӘР

Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясендә белем алу

«Цифрлы икътисад өчен кадрлар» төбәк проекты кысаларында 2022 елда бөтен Татарстаннан 244 дәүләт һәм муниципаль хезмәткәр яңадан укытылды. Укыту программалары өчәү иде:

### ПРОГРАММА

228 академик сәгать

**«Цифрлы трансформация проектларын гамәлгә ашыру»**

РФ субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары җитәкчеләренә, шулай ук аларның урынбасарларына юнәлдерелгән.

### ПРОГРАММА

60 академик сәгать

**«Цифрлы трансформация һәм цифрлы икътисад: технологияләр һәм компетенцияләр»**

РФ субъектлары дәүләт хакимияте органнарының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә

### ПРОГРАММА

20 академик сәгать

**«Дәүләт һәм муниципаль идарәдә цифрлы трансформация нигезләре»**

Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләренә юнәлдерелгән.

## STEPIK ОНЛАЙН БЕЛЕМ БИРҮ ПЛАТФОРМАСЫ

**нәтиҗәләр**

**88 000**

2022 елда республикада бюджет өлкәсенең шул кадәр хезмәткәре – дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр һәм ведомство карамагындагы оешмалар хезмәткәрләре Цифрлы трансформация нигезләрен ача торган база курсларында укулар уздылар.

## «ЦИФР ДӘРЕСЕ» РОССИЯКҮЛӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ПРОЕКТЫ

2022 елда республиканың белем бирү йортларында алты дәрес оештырылды һәм үткәрелде:

- «Квант дөньясы: квант компьютеры ни рәвешле корылган»;
- «Кушымталарны тиз арада эшләп чыгару»;
- «Цифрлы Ликбез»;
- «Цифрлы сәнгать: ИТ өлкәсендә музыка»;
- «Стартапларда ясалма интеллект»;
- «Видеотехнологияләр».





2022 ел дәвамында төрле яшьтәге мәктәп укучылары өчен Цифрлаштыру елы кысаларында, белем бирү йортларында һәм җәйге ял лагерьларында республиканың CDTO тарафыннан ай саен Цифр дәресләре үткәрелде

### 1-11 сыйныф укучылары көнүзәк темалар турында фикер алыштылар:

- Интернетта үз-үзеңне тоту куркынычсызлыгы
- Ясалма интеллект
- Виртуаль һәм киңәйтелгән чынбарлык
- Клиентка үзәкләштерелгән дәүләт
- Индустрия 4.0. Сәнәгатьтә цифрлы технологияләр
- Киләчәк технологияләре. Квант компьютеры
- Пилотсыз машина технологиясе
- Яңа цифрлы сәнгать
- Ничек итеп IT-эшкуар булырга
- Тормыш өчен болыт сервислары.

## нәтиҗәләр

**616**
дәрес

**> 1 400**
артык мәктәбе

**280 000**
артык Татарстан укучысы

## «ЦИФРЛЫ ҺӨНӘРЛӘР» ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАСЫ

**нәтиҗәләр**

**7446 кеше**

проект кысаларында 2022 елда ИТ өлкәсендә яңа белгечлек алган

**топ 5**

Татарстан проектта катнашу активлыгы буенча лидерлар бишлегенә эләкте

2021 елдан башлап Татарстан цифрлы икътисад өлкәсендә «Цифрлы һөнәрләр» өстәмә белем бирү дәүләт программасында актив катнаша.

Проектның операторы – 2035 Университетының Цифрлы икътисад өчен кадрлар буенча компетенцияләр үзәге.

## «КИЛӘЧӘК КОДЫ»

Россия Цифр министрлыгыннан «ИТ-тармакның кадрлар потенциалын үстерү» федераль проекты нигезендә «Цифрлы икътисад» илкүләм программасы проектларының берсе.

Белем бирү проектының операторы – 2035 Университеты.

Россиянең барлык төбәкләреннән 8-11 сыйныф укучылары онлайн-форматта укый ала. Укыту ике ел дәвам итә һәм 144 академик сәгать һәм 4 укыту модулен үз эченә ала.

**нәтиҗәләр**

**6 000**

Татарстаннан гаризалар саны



## ЯНДЕКС АКАДЕМИЯСЕ ЛИЦЕЕ

Яндексның Pythonda программалаштыру проектында 8-9 сыйныф укучылары укый, шулай ук укытучылар базасы һәм IT-кадрлар үсеш ала. Проект Татарстанда 2017 елдан бирле эшли.

### Бүген Татарстанда

- Казан
- Иннополис
- Зеленодольск
- Чистай һәм
- Мамадышта
- Чаллы
- Әлмәт
- Бөгелмә
- Алабуга
- Азнакай
- Алексеевск
- Менделеевск
- Балык Бистәсе

### нәтиҗәләр

**2 000**

барлык вакыт дәвамында укыган укучылар саны

**500**

2022/2023 уку елы башына проектта катнаша торган республика укучылары




## «МӘКТӘП 21» («ШКОЛА 21»)

Сберның инновацияле белем бирү проекты сайлап алу этапларын уңышлы узган 18 яшьтән өлкәнрәк һәркемгә ИТ өлкәсендә бушлай кирәкле белем алу мөмкинлеген бирә.

### Мәктәп методикасы

«тиңдәшкә тиңдәш» – укытучыларсыз, лекцияләр һәм билгеләрдән башка белем бирү. Ул проектлар өстендә индивидуаль яки күмәк эшләүгә генә корыла. Шул ук вакытта һәр студент мөстәкыйль рәвештә уку графигын төзи һәм индивидуаль белем бирү траекториясе буйлап хәрәкәт итә.

## Укучылар өчен төрледән төрле юнәлешләр бар:

- Мобиль эшләнмә
- Машина ярдәмендә өйрәнү һәм мәгълүматларны анализлау
- Компьютер графикасы һәм GameDev
- Frontend һәм Backend
- Акыллы җайланмаларны программалаштыру
- DevOps
- Робот техникасы (ROS) һәм электроника
- Алгоритмнар һәм белешмә структуралары
- Белешмәләр базасы
- Веб-программалаштыру
- Киберкуркынычсызлык
- Операция системалары эшләү
- Челтәрләр һәм система белән идарә итү
- Программа тәэминаты архитектурасы
- Программалаштыру телләре.

Казанда «Мәктәп 21» («Школа 21») ел саен ИТ-өлкәгә 600 белгеч укытып чыгарырга планлаштыра, бу исә хезмәт базарын сыйфатлы тулыландырачак. Инде 2023 елда ук беренче 200 яңа белгеч чыгарылыр дип көтелә.





# ИТ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ БЕЛГЕЧЛЕКЛӘР БУЕНЧА УКЫТУЧЫ ЮГАРЫ ҺӘМ УРТА ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ ЙОРТЛАРЫ

## НӘТИҖӘЛӘР

**4 464**
2022 елда ИТ өлкәсендәге белгечлекләр буенча укытып чыгарылган студентлар саны

**шулардан**

**3 063**
югары белем буенча

**1 401**
урта һөнәри белем буенча

### Татарстан Республикасының югары белем бирү программалары буенча укытучы 11 белем йорты.

Югары уку йортлары:

- Казан (Идел буе) федераль университеты
- 2. Казан милли тикшеренү технология университеты
- 3. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ
- 4. Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты
- 5. Казан дәүләт энергетика университеты
- 6. Чаллы дәүләт педагогика университеты
- 7. "ТИСБИ" идарә университеты
- 8. В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты
- 9. Социаль белем бирү академиясе
- 10. Социаль һәм гуманитар белемнәр институты
- 11. Иннополис университеты.

Республиканың урта һөнәри белем бирү программалары буенча укыта торган 29 белем йорты, алар арасында 5 югары уку йорты һәм 24 урта һөнәри белем йорты.




# КФУ МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ИНТЕЛЛЕКТУАЛЬ СИСТЕМАЛАР ИНСТИТУТЫНЫҢ ИҢ ЯХШЫ СТУДЕНТЛАРЫНА ГРАНТЛАР

ИТ-өлкәдә «Программалы инженерия» юнәлеше буенча белем бирү буенча КФУ Мәгълүмат технологияләре һәм интеллектуаль системалар институтының иң яхшы студентларына ярдәм итүгә корылган эшчәнлек юнәлешләренең берсе – Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан грантлар бирү.

## Грантларны бирү максатлары

- бөтен Россиядән һәм БДБ илләреннән иң яхшы абитуриентларны җәлеп итү
- яхшы өлгерүчәнлеккә этәргеч ясау, чөнки грант бер елга бирелә
- республика территориясендә теркәлгән предприятиеләрдә белгечлекләре буенча мәҗбүри эшләтеп, иң яхшы чыгарылыш укучыларын – грант алучыларны Татарстан Республикасында саклап калу.

## нәтиҗәләр

**22,7** млн.сум

2022 елда «Цифрлы икътисад өчен кадрлар» төбәк проекты кысаларында финанс белән тәэмин итү күләме

**163**

грант бирелгән

# DIGITALSKILLS

2022 елның 21-24 сентябрендә Татарстанда «Казан Экспо» ХКҮ базасында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә DigitalSkills IV тармак чемпионаты узды.

Татарстан Республикасы җыелма командасын чемпионатның барлык 29 компетенциясе буенча 48 конкурсант һәм 35 эксперт тәкъдим итте. Республика өчен өстәмә рәвештә «ТатИТнефть» ҖЧҖ оешмасыннан ике конкурсант җыелма команда составыннан тыш катнашты.

**Татарстан Республикасы җыелма командасы**

**48** конкурсант

**35** эксперт

**нәтиҗәләр**

**9** алтын медаль

**7** көмеш медаль

**7** бронза медаль








## «КВАНТОРИУМ» БАЛАЛАР ТЕХНОПАРКЫ

Югары технологияле җиһазлар ярдәмендә белем бирү мәйданчыклары, балаларга өстәмә белем бирүнең яңа моделен гамәлгә ашыру өчен, Россия Федерациясенең яңа проектларын алга этәрү буенча стратегик инициативалар агентлыгы башлангычында 2016 елдан бирле эшли. Максаты – яшь инженер кадрларны әзерләү, инновацияле технологияләр һәм идеяләр булдыру, аларны сынап карау һәм гамәлгә кертү.

Татарстанда технопарклар Чаллыда, Түбән Камада һәм Әлмәттә эшли. Дәресләр 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге барлык балалар өчен дә бушлай.

### Гамәлдәге юнәлешләр

- Энерджиквантум
- Наноквантум
- Нейроквантум
- Геоквантум
- Робоквантум
- Сәнәгый дизайн

### нәтиҗәләр

**3 000**

2022 елда технопаркларда белем алган балалар саны

# «ХАЛЫКАРА КОМПЕТЕНЦИЯЛӘР ҮЗӘГЕ – КАЗАН МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ ТЕХНИКУМЫ» ДАҺБУ

Бу ИТ һәм телекоммуникацияләр өлкәсендә урта звено белгечләрен әзерли торган, динамикалы рәвештә үсеш алучы өйрәнү мәйданчыгы. Үзәкнең заманча укыту-матди базасы һәм югары фәнни-җитештерү потенциалы бар.

2022 елда Үзәккә Федераль инновация мәйданчыгы дәрәҗәсе бирелде. Аның максаты – төп гомуми белем базасында гамәлгә ашырыла торган урта һөнәри белем бирү программаларының һөнәри юнәлешен исәпкә алып, гомуми белем бирү дисциплиналары буенча әзерлек практикасын яңарту өчен методик эшләнмәләрнең федераль тупланмасын гамәлгә кертү.

## нәтиҗәләр

### 1 нче урын

WorldSkills Russia – 2022 Евразия чемпионатынд

### 1 нче урын

мобиль робот техникасы компетенциясе буенча 2022 BRICS Skills Competition (BRICS Future Skills Challenge) бәйгесендә дә алтын призер

Федераль инновацияләр мәйданчыгы статусы бирелде








## нәтиҗәләр

**1 600**

студент

**294**

2022 елда диплом алучы чыгарылышлар саны

«Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» ДАҺБУ мәйданчыкларында ИТ-компетенцияләр буенча һөнәри осталыкның WorldSkills Russia төбәк һәм сайлап алу ярышлары уздырыла, ИТ-компетенцияләр буенча Россия, Татарстан Республикасының киңәйтелгән җыелма командасы составын төрле, шул исәптән халыкара ярышларга әзерләү эшчәнлеге алып барыла.

2022 елда Саранскида Үзәк командасы а 1 нче урынны яулады. Үзәк командасы шулай ук мобиль робот техникасы компетенциясе буенча 2022 BRICS Skills Competition (BRICS Future Skills Challenge) бәйгесендә дә алтын призер булды.



## IT-CUBE

«Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» ДАҺБУ базасында оештырылган Балаларның ИТ-иҗат үзәге. Төп бурычы – укучыларны мәгълүмат технологияләре, робот техникасы һәм IT-инжиниринг өлкәсендә инновацияле, гамәли юнәлешле эшчәнлеккә җәлеп итү.

### Уку юнәлешләре:

- Мобиль робот техникасы
- VR/AR кушымталар эшләү
- Система белән идарә итү
- Кибергигиена
- Мобиль эшләнмә
- Программалаштыру.

### нәтиҗәләр

**800**

2022 елда белем алган кешеләр саны

# ТЕЛЕКОММУНИКАЦИЯ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ



# ТЕЛЕКОММУНИКАЦИЯ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ

## МОБИЛЬ ЭЛЕМТӘ

### нәтиҗәләр

**7,56 млн** - 3%
мобиль элемтә абонентлары саны

**720 286 Тбайт** + 19%
күчмә элемтә челтәрләрендәге трафик

**4,6 млн** + 3%
мобиль интернет абонентлары саны

**17 Гбайт** + 2 Гбайт
мобиль интернеттан 1 кулланучыга аена туры килә торган трафик

Элемтә операторлары, Татарстанда яшәүчеләрне югары тизлекле мобиль интернет һәм сыйфатлы тавыш элемтәсе белән тәэмин итү өчен, 2G, 3G һәм 4G стандартларына туры килә торган мобиль элемтәнең 30000 артык база станциясен төзеделәр. 2022 елда Татарстанда элемтә сыйфатын алга таба яхшырту өчен, мобиль элемтәнең 800дән артык радиоэлектрон чарасы (база станцияләре) теркәлде.

**30 680**
база станциясе төзелде

**830**
база станциясе 2022 елда төзелде

**Клиентларга күрсәтелә торган сервисның сыйфат дәрәҗәсен саклап калу өчен, элемтә операторлары 4G дәрәҗәсендә эшли торган база станцияләрен күбрәк урнаштыралар.**



# ПРОЕКТ УЦН 2.0

## НӘТИҖӘЛӘР

**61**

торак пункт база станцияләрен урнаштыру буенча 2022 ел планына кертелде

## ПЛАННАР

**55**

торак пункт база станцияләрен урнаштыру буенча – 2023 ел планына



Татарстан Республикасында цифрлы тигезсезлекне бетерү өчен, федераль инфраструктура проектлары гамәлгә ашырыла.

2022 елда халык саны 100дән 500 кешегә кадәр исәпләнгән авыл торак пунктларын мобиль элемтә һәм интернет белән тәэмин итү буенча федераль программа гамәлгә ашырыла башлады.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында тавыш бирү нәтиҗәсендә Татарстанның 61 торак пунктыннан торган исемлек билгеләнде, аларны мобиль элемтә һәм интернет белән колачларга кирәк. 44 торак пунктта «Ростелеком» ГАҖ компаниясе тарафыннан база станцияләре урнаштырылачак, хәзерге вакытта эшләр бара һәм 2023 елның 1 кварталында тәмамланачак. Тагын 17 торак пунктта мобиль элемтә хезмәтләре башка элемтә операторлары тарафыннан күрсәтелә инде.

База станцияләрен урнаштыру планына 2023 ел ахырына кадәр тагын 55 торак пункт керә. Әлеге торак пунктлар шулай ук Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында бөтен халык тарафыннан тавыш бирү юлы белән сайлап алынды. Сайланган торак пунктлар хәзерге вакытта тикшерелә.



## GPON ТЕХНОЛОГИЯСЕ БУЕНЧА ЧЕЛТӘРЛӘР ТӨЗҮ

### НӘТИҖӘЛӘР

**1,2 млн**
2022 ел нәтиҗәләре буенча Татарстанда югары тизлекле чыбыклы интернет абонентлары саны

**132**
торак пункт GPON челтәрләре белән җиһазландырылган

**116 000**
төзелгән порт

### ПЛАННАР

**> 100 000**
артык йорт хуҗалыгы 2023 елда оптик челтәр алачак

**Татарстанда югары тизлекле интернет челтәрләрен төзү эше оештырылды**



## МӘКТӘПЛӘРНЕҢ ИТ-ИНФРАСТРУКТУРАСЫ

**нәтиҗәләр**

**124**

мәктәп бинасы Wi-Fi челтәрләре белән тәэмин ителгән һәм керү төркемнәрендә видеокамералар урнаштырылды

**488**

Видеокамера урнаштырылды

**2 611**

Wi-Fi ноктасы урнаштырылды

**180,6 млн.сум**

проектны гамәлгә ашыру өчен федераль һәм республика бюджетыннан бүлеп бирелде

Проектның үзенчәлеге – кулланучылар Wi-Fi челтәреннән Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында исәпкә алу язуы аша файдалана. Китертелгән барлык җиһазлар да Россиядә җитештерелгән.

# БЮДЖЕТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕН, ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХАКИМИЯТ ОРГАННАРЫН ИНТЕРНЕТ ЧЕЛТӘРЕНӘ ТОТАШТЫРУ

## НӘТИҖӘЛӘР

**1 718**

уку йорты (мәктәпләр, техникумнар, көллиятләр) 2022 елда белешмәләр тапшыруның бердәм челтәренә тоташтырылды

## ПЛАННАР

элемтәнең телефон линияләре буенча тоташтыруның искергән технологияләрен элемтәнең оптик линияләре буенча югары тизлекле тоташтыруга күчерү эшен дәвам иттерү

| Тоташтыру технологиясе | Объектлар саны |
|---|---|
| Элемтәнең җепселле-оптик линияләре | 6 993 |
| Бакыр элемтә линиясе (ADSL) | 3 575 |
| Тоташтыруның чыбыксыз технологияләре | 190 |
| **БАРЛЫГЫ** | **10 758** |

Татарстан Республикасында 10 меңнән артык бюджет учреждениесе, дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары интернетка тоташтырылган. 2022 елда мәктәпләр, техникумнар һәм көллиятләр федераль челтәр аша «Ростелеком» ГАҖ элемтә операторы тарафыннан белешмәләр тапшыруның бердәм челтәренә тоташтырылган.



# ПОЧТА ЭЛЕМТӘСЕ БҮЛЕКЧӘЛӘРЕН РЕМОНТЛАУ

**1 111**

Татарстан Республикасы территориясендә почта элемтәсе хезмәтләрен 1111 почта бүлекчәсе күрсәтә, шуларның

**851**

авыл һәм

**260**

шәһәр

## Почта элемтәсе бүлекчәләрен ремонтлау

- Аксубай
- Иске Ибрай авылы
- Актаныш
- Пучы авылы
- Алексеевск
- Биләр авылы
- Әлмәт
- Рус Акташы авылы
- Әтнә
- Олы Әтнә авылы
- Биектау
- Шәпше авылы
- Чүпрәле
- Кече Чынлы авылы
- Зеленодольск
- Норлат авылы
- Лаеш
- Столбище авылы
- Яңа Чишмә
- Яңа Чишмә авылы
- Тукай
- Кече Шилнә авылы
- Тукай
- Шилнәбаш авылы
- Теләче
- Теләче авылы
- Чистай
- Каргалы авылы
- Ютазы
- Ютазы авылы

## НӘТИҖӘЛӘР

- 2022 елның 3 маенда «Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел» рәсемле маркасы чыгарылды.
- 2022 елның 13 декабрендә «Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы» рәсемле маркасы белән конверт чыгарылды.
- Татарстан Республикасында почта элемтәсе бүлекчәләрен ремонтлау федераль программасы кысаларында Россия Федерациясендә беренчеләрдән булып 15 авылның почта бүлекчәсендә модернизация үткәрелде.

## ПЛАННАР

- Татарстан Республикасында почта элемтәсе бүлекчәләрен ремонтлау федераль программасы кысаларында 2023 елда 100 авылның почта бүлекчәсендә модернизация үткәрергә. Беренче этапка почта элемтәсенең 46 авыл бүлекчәсе кертелде.
- Габдулла Тукай исемендәге Халыкара аэропорт янында Казан логистика почта үзәге территориясендә бонд складының сынау зонасын оештыру.
- Идел буе федераль округы буенча автотранспорт узелын һәм автомобильләргә газ салу компрессор станциясен (АГНКС) проектлау.









## «ЧИСТА КҮК ЙӨЗЕ» («ЧИСТОЕ НЕБО») ПРОЕКТЫ

### НӘТИҖӘЛӘР

**80, 7 км**

асылмалы элемтә линияләре операторлар тарафыннан җир астына күчерелде.

**1 100 км**

мең км «асманы» бетерергә кирәк. Шуның 545 км Казанда урнашкан.

**116 млн. сум**

2022 елдагы инвестицияләр күләме.

Программа 2011 елда башланып китте. Инвентарьлаштыру нәтиҗәләре буенча 3,7 мең километр озынлыгында асылмалы элемтә линиясенең булуы ачыкланды.

### ПЛАННАР

**90,7 км**

асылмалы элемтә линиясен җир асты коммуникацияләр енә күчерү.

**100 млн**

Инвестицияләр күләме 100 млн.сумнан артык планлаштырылган.

## КУРКЫНЫЧСЫЗ ШӘҺӘР

### НӘТИҖӘЛӘР

Республика халкының иминлеген тәэмин итү өчен, мәйданчыклар, парклар, скверлар, социаль инфраструктура объектлары (балалар бакчалары, мәктәпләр һ.б.), күпфатирлы йортлар кебек төрле объектларда, транспорт инфраструктурасы объектларында 67 меңгә якын видеокамера урнаштырылды.

Республиканың җәмәгать урыннарында 4,6 мең видеокамера урнаштырылды.

Күпфатирлы йортларда 23,8 мең видеокамера урнаштырылды.

### ПЛАННАР

2023 елга җәмәгать зоналарында 1127 артык камера урнаштырырга һәм видеокүзәтүнең бердәм интеграцион платформасын булдыруга керешергә планлаштырыла.

**Элемтә операторлары тарафыннан торак фондтагы домофон системасын модернизацияләү буенча актив эш алып барыла. Видеоархивлы видеодомофоннар урнаштырыла.**





# ФӘН ҺӘМ ТЕХНОЛОГИЯ

Татарстанда фәнни-мәгариф комплексы, шул исәптән телекоммуникацияләр өлкәсендә дә, үсеш алып барыла.

Импортны алмаштыру һәм «Цифрлы икътисад» илкүләм программасы максатларына ирешү өчен, ТР Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ һәм Казан милли тикшеренү технология университеты – КАИ белән берлектә үзебезнең илдә LTE/4G-5G-NG технологияләре җиһазларын җитештерү эшен башкаралар.

Фәнни-мәгариф комплексы үсешенең тагын бер юнәлеше – компьютерлар һәм серверлар өчен басма такталар эшләү һәм җитештерү мәсьәләсе. Казан милли тикшеренү технология университеты – КАИ шулай ук микроэлектрон җайланмаларны эшләү һәм җитештерү линияләренә хезмәт күрсәтүдә ICL КПО-ВС басма такталарын җитештерү заводын тәэмин итү өлкәсендә белгечләр әзерләү юнәлешен дә көчәйтә. Бу эш хәзерге вакытта А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү университеты, «В.И.Шимко исемендәге «Радиоэлектроника» ФҖБ» АҖ һәм «АйСиЭл Техно» ҖЧҖ белән берлектә уздырыла.

# 04

# МӘГЪЛУМАТИ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК



# МӘГЪЛҮМАТИ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК

Белгечләр белешмәләрне саклау, системаларның җитешсезлек дәрәҗәсен киметү, яңа эш алымнарын һәм технологияләрен кертү, шулай ук әлеге тармакта белгечләр әзерләү буенча бердәм сәясәт үткәрәләр.

## ИТОГИ

- Мәгълүмат системаларын саклауның сертификацияләнгән чаралары кертелде, Россия Техник һәм экспорт контрольлеге буенча федераль хезмәт таләбе буенча «Электрон сәламәтлек саклау» дәүләт мәгълүмат системасына аттестация үткәрелде
- Россия Федерациясе мәгълүмат ресурсларына компьютер һөҗүмнәре нәтиҗәләрен ачыклау, кисәтү һәм бетерү дәүләт системасы кысаларында Компьютер инцидентлары буенча илкүләм координация үзәге белән хезмәттәшлек оештырылды
- Дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләре өчен «Мәгълүмати куркынычсызлык» программасы буенча квалификация күтәрү курсы оештырылды

## ПЛАННАР

- Дәүләт хакимияте органнарының 10 белгече өчен мәгълүмати куркынычсызлык буенча яңадан укытуны оештыру
- Дәүләт мәгълүмат системаларын аттестацияләү буенча планлы эшләрне дәвам иттерү
- 2023 елда мәгълүматларны саклау таләпләренә туры килү аттестатларының вакыты чыга торган республика җирле үзидарә органнарының автоматлаштырылган эш урыннарын аттестацияләүне дәвам иттерү.

# «МӘГЪЛҮМАТИ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК» ТӨБӘК ПРОЕКТЫ

«Мәгълүмати куркынычсызлык» проекты кысаларында шәхесне, җәмгыятьне һәм дәүләтне эчке һәм читтән килә торган мәгълүмат куркынычларыннан саклауга юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырыла. Мисал өчен, чиктән тыш мәгълүмат инфраструктурасының республика объектларында мәгълүмат куркынычсызлыгы дәрәҗәсен һәм мәгълүмати куркынычсызлык буенча белгечләр санын арттыру.

**74** млн.сум
мәгълүмат системаларының мәгълүмати куркынычсызлык системаларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау күләме

## ЦЕНТР ПРЕДОТВРАЩЕНИЯ КИБЕРУГРОЗ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

### НӘТИҖӘЛӘР

**375 000**

Хөкүмәтнең Белешмәләрне эшкәртү үзәгендәге мәгълүмат системаларында теркәлгән һәм эшкәртелгән инцидентлар күләме

**> 3,5 Гбит артык**

чагылдырылган DDoS-һөҗүмнәр егәрлеге

**> 12 млрд. артык**

Хөкүмәтнең Белешмәләрне эшкәртү үзәгендә мәгълүмат системаларына карата легитимлы булмаган, фильтр аша үткәрелгән гаризалар саны

**> 15 000**

һөҗүмче IP-адрес чикләтелгән

Үзәк хөкүмәтнең Белешмәләрне эшкәртү үзәгендә мәгълүматны саклауның тулы спектрын тәэмин итә.

**> 2 400**

артык

сервер сканирование аша уздырылган

### ПЛАННАР

- Кибер-куркынычларны булдырмый калу үзәге хезмәткәрләрен яңа ысулларга һәм технологияләргә һәм, хөкүмәтнең Белешмәләрне эшкәртү үзәге мәгълүмат ресурсларын нәтиҗәлерәк саклау өчен, тиешле норматив-хокукый актларга өйрәтү
- Кибер-куркынычларны анализлау һәм аларга каршы торуның аппарат программасы чараларын киңәйтү
- МК өлкәсендә мәгълүмат һәм белемнәр уртаклашуның нәтиҗәлелеген арттыру өчен, башка оешмалар һәм агентлыклар белән партнерлык элемтәләрен киңәйтү

05

# ИМПОРТНЫ АЛМАШТЫРУ



# АППАРАТ БЕЛӘН ТӘЭМИН ӨЛКӘСЕНДӘ ИМПОРТНЫ АЛМАШТЫРУ

«АйСиЭл Техно» ҖЧҖ компаниясе компьютерларда һәм сервер җиһазларында кулланылачак басма платаларны чыгару линиясен эшләтеп җибәрергә җыена. Аны 2023 елда файдалануга тапшыру планлаштырыла.

# ПРОГРАММА ТӘЭМИНАТЫ БУЕНЧА ИМПОРТНЫ АЛМАШТЫРУ

**24 000**

Барлык Татарстан укытучыларына бирелгән, Астра Линукс һәм Альт Линукс операция системалары белән үзебездә җитештерелгән ноутбуклар саны

## НӘТИҖӘЛӘР

- Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен илебездә булдырылган бердәм коммуникация системасы кертелде
- ТР Цифр министрлыгында үзебездә җитештерелгән Альт Линукс, Астра Линукс һәм РедОС операция системаларына сынау эксплуатацияләре үткәрелде
- ТР Цифр министрлыгында Р7 офис һәм Мой офис кушымталары өчен үзебездә җитештерелгән офис кушымталары пакетларына сынау уздырылды

## ПЛАННАР

- Татарстан дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары хезмәткәрләрен импортка бәйсез булган программа тәэминатында (операция системасы, офис кушымталары пакеты, почта кушымтасы) укытуны дәвам иттерү
- Республикада булган мәгълүмат системаларын үзебездәге операция системаларында эшләүгә яраклаштыру.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯ ҮЗӘГЕ



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЦИФРЛЫ ТРАНСФОРМАЦИЯ ҮЗӘГЕ

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән 2019 елда төзелде. ЦТҮ командасы гамәлдәге сервисларны һәм күрсәтелә торган хезмәтләрне цифрлаштыру, «Цифрлы икътисад» илкүләм программасы бурычларын хәл итү, республикада яшәүчеләр өчен яңа цифрлы продуктлар булдыру, шулай ук республика муниципаль берәмлекләренең башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнарын цифрлы трансформацияләү белән шөгыльләнә.

**ЦТҮ миссиясе – гражданнарның һәм бизнесның дәүләт белән гади һәм уңайлы хезмәттәшлеге.**

ЦТҮ – Татарстан Республикасын цифрлаштыру кысаларында бердәм дәүләт заказчысы һәм проект офисы.

Также ГКУ «ЦЦТ РТ» оказывает техподдержку и модернизирует уже существующие ведомственные системы.

## ИТОГИ

**399**
төзелгән контрактлар һәм шартнамәләр саны

**154,9 млн.сум**
янга калган акча

### Төп проектлар:

- «Мин төзим»
- «Минем субсидияләр»
- «Кайгырту»
- «Мин – мәктәп укучысы»
- «Локоло»

Мәгълүмат системалары, ясалма интеллект базасында ярдәмче Лилия, Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү мәгълүмат системасы, Белешмәләр фабрикасы һ.б.

**99,7 %**
дәүләт программаларын үзләштерү

**100 %**
федераль акчаларны үзләштерү

**88,7 %**
министрлар Кабинеты күрсәтмәләрен үзләштерү



# ЭЛЕКТРОН ДОКУМЕНТ ӘЙЛӘНЕШЕ

Система дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы бюджет оешмаларында эш башкару һәм документлар белән алмашу процессларын автоматлаштыру өчен билгеләнгән

## нәтиҗәләр

**10 000**
Көн саен 10 мең документ төзелә

**50, 5 мең**
теркәлгән кулланучы

**320 ТБ**
күләмендә документлар

**20 000**
Көн саен 20 мең резолюция

**83**
модернизация

## ПЛАННАР

- хезмәттә файдалану өчен документлар белән алмашу эшләрен төгәлләү
- система интерфейсын яңарту






# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮ ПОРТАЛЫ

**2,9 млн**
шәхси кабинет

**502**
хезмәт һәм сервис күрсәтелә

**26,4 млрд.сум**
портал аша үткәрелгән түләүләр

## Кызыклы белешмәләр

- порталда минут саен электрон рәвештә 507 хезмәт күрсәтелә
- һәр дүртенче гаилә ТКХ хезмәтләре өчен портал аша түли
- һәрбер кулланучы 8 сәгатькә кадәр вакытын янга калдыра

**К началу декабря 2022 года Татарстан первым в России перевёл все государственные и муниципальные услуги в электронный вид**

**319**

значимых услуг доступно жителям республики в электронном виде

### 1 нче сыйныфка электрон язылу

Хезмәт тулысынча цифрлы: электрон гариза ата-аналар шәхсән биргән гариза кебек үк карала

**32 577**

бу чорда Татарстанның дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталы аша 1 сыйныфка бирелгән электрон гаризалар саны

### Такси лицензияләү

**5 500**

хезмәт күрсәтелә башлаганнан соң бирелгән электрон гаризалар саны

### Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы

**3 652**

тапшырылган электрон гаризалар саны

### Көллиятләргә электрон гаризалар бирү

**15 405**

хезмәт күрсәтелә башлаганнан соң бирелгән электрон гаризалар саны

### Реклама корылмасын урнаштыру һәм файдалану өчен рөхсәт бирү

**430**

бирелгән рөхсәтләр саны

## НӘТИҖӘЛӘР

- 164 социаль әһәмиятле хезмәт чыгарылды
- «Юлларда ярдәм картасы» яңа сервисы булдырылды
- юридик затлар өчен салым бурычы турында хәбәр итү сервисы булдырылды

## ПЛАННАР

- Порталда чат-бот кертү
- Портал һәм «ТР хезмәтләре» МП хәбәрләр һәм белдерүләр җибәрүне оптимальләштерү
- Порталның веб-версиясен мобиль платформаларга яраклаштыру
- UX-Порталын үзгәртү
- Порталда начар күрүчеләр өчен режим булдыру



# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘСМИ ПОРТАЛЫ

Портал республика дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын һәм үтемлелеген арттыру, шулай ук интернет челтәре аша төбәкнең икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни потенциалын күрсәтү турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән.

Иң актив аудитория: 25-34 яшьтәгеләр – 29,6 %

**107 млн**
2022 елда Татарстан Республикасы рәсми порталы сайтларын караучылар саны –

**9**
яңа сайтлар булдырылды

## 2022 елда иң күп файдаланыла торган топ-5 сайт

**3,4 млн**
караучы

Татарстан Республикасы Президенты сайты

**2,6 млн**
караучы

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

**1,97 млн**
караучы

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайты

**1,79 млн**
караучы

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы сайты

**1,68 млн**
караучы

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы сайты



## ҮЗӘКЛӘШТЕРЕЛГӘН БУХГАЛТЕРИЯ

Татарстан Республикасы бюджет системасы өчен бухгалтерлык, кадрлар исәбе һәм хезмәт хакын исәпләү бурычларын хәл иту системасы. Бюджет үтәлеше турында еллык, кварталлык һәм айлык хисапны төзергә, җыярга һәм тапшырырга булыша.

**> 8 200**
мең учреждение

**> 15 000**
мең кулланучы

**> 36 млн**
үткәру

### НӘТИҖӘЛӘР

- Татарстан Республикасы кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы белән интеграллаштырылды
- «Бухгалтерия» ярдәмче системасы яңартылды
- «Хезмәт хаклары һәм Кадрлар» ярдәмче системасы яңартылды

### ПЛАННАР

- финанс документларының электрон документ әйләнеше
- керемнәр белән идарә иту



# ТР ПРОСТРАНСТВО БЕЛЕШМӘЛӘРЕ ТӨБӘК ПОРТАЛЫ (ГЕОПОРТАЛ РТ)

Татарстан территориясе буенча пространство белешмәләренең бердәм цифрлы саклау урынын формалаштырырга булыша. Система республиканың территориаль үсешен билгели торган барлык атрибутив белешмәләрдән ведомствоара файдалану мөмкинлеген бирә

**1 044**
мәгълүмат катламы

**20 707**
ГТХМ объекты

**57 750**
видеокүзәтү камерасы

## ПЛАНЫ

- Порталны министрлыклар һәм ведомстволар биргән белешмәләр белән тулыландыру

**4 376**
мәдәни мирас объекты

**1540**
инвестиция объекты һәм инвестиция инфраструктурасы объектлары




# БЕЛЕШМӘЛӘР ФАБРИКАСЫ




- Товарның исеме
- Товарның бәясе
- Төргәкләр саны
- Муниципаль район
- Өстәмә хак салымы (10%, 20%)
- Смена номеры
- Сменада чек номеры

**900 млн**

чек анализланды

## Анализ стоимости услуг ЖКХ, млн рублей




ТКХ хезмәтләре турындагы белешмәләрне анализлау исәпләнгән түләүләрдәге дисбалансны ачыкларга ярдәм итәчәк

## нәтиҗәләр

Сервис нигезендә булдырылган мәгълүмат системалары:

- * Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге аналитикасы – эшкуарлык бергәлегенә контроль (күзәтчелек)/профилактик чараларның структур һәм сан составы турында мәгълүмат бирү өчен
- * Товар агымнарына аналитика. ТР Икътисад министрлыгы товарларны сату юнәлешләрен, шулай ук предприятиеләрнең һәм халыкның аларга булган ихтыяҗын автомат рәвештә ачыклау мөмкинлегенә ия булды
- белешмәләр белән идарә итүнең илкүләм системасы белән интеграция көйләнде
- Фабрика РФ Федераль салым хезмәтенең читтән белешмәләр алу платформасына интеграллаштырылган. Бу Татарстан территориясенә кертелә торган продукция күләмен, шулай ук республиканың сәүдә челтәрләре һәм предприятиеләре базарындагы өлешен җиңеләйтәчәк
- азык-төлек иминлегенә бәясе ягыннан күзәтчелек итү буенча башкарма комитетлардагы белгечләрнең эш вакытын кыскарту өчен социаль әһәмиятле булган товарларның 52 категориядә автоматик классификаторы эшләнде
- зур белешмәләрне анализлау өлкәсендә дәүләт хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү программасы эшләнде һәм сынап каралды

## ПЛАННАР

- дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләрен Белешмәләр фабрикасы чараларын кулланып, мөстәкыйль аналитика алымнарына әзерләү
- дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен республика мәгълүмат системаларының үтемлелек дәрәҗәсен арттыру
- дәүләт хакимияте башкарма органнарында, җирле үзидарә органнарындагы белешмәләр нигезендә идарәи проектларны гамәлгә ашыру хисабына кабул ителә торган карарларның ачыклык дәрәҗәсен арттыру




## КИРЕ ЭЛЕМТӘ ПЛАТФОРМАСЫ (КЭП)

Татарстанда яшәүчеләр РФ Дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталы, оешмалар сайтларындагы виджетлар һәм «Бергә хәл итәбез» («Решаем вместе») мобиль кушымтасы аша дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына төрле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгатьләр җибәрә ала. Шулай ук әлеге платформа аша сораштыруларда, тавыш бирүләрдә һәм иҗтимагый фикер алышуларда да катнаша алалар.

**НӘТИҖӘЛӘР**

**33 925**
мөрәҗәгать

**31 397**
хәл ителгән (95%)

**СОРАШТЫР-УЛАР**

**558**
муниципальных

**5**
төбәк

**ТАВЫШ-БИРҮЛӘР**

**2**
проект буенча

# ХАЛЫК КОНТРОЛЕ

126 категория буенча гражданнардан мөрәҗәгатьләр кабул итеп, халык белән хакимият арасында үзара хезмәттәшлекнең популяр чараларының берсе. Система территорияләрне төзекләндерү, юллар торышы, поликлиникаларга, балалар бакчаларына йөрүне оештыру кебек мөһим мәсьәләләр турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә.

## НӘТИҖӘЛӘР

**> 91 000**

меңнән артык белдерү бастырылган

**70 000**

мең гариза (барлык гаризаларның 77%) хәл ителгән

10 ел эчендә беренче тапкыр системаның веб-версиясенә редизайн ясалды

ТКХ юнәлеше буенча белдерүләр җиткерелә ала

**> 300**

артык гариза көн саен килә

25-34 яшьлек хатын-кызлар

күпчелек очракта веб-версиядән файдалана

## ПЛАННАР

- системадан автоматик рәвештә алына торган статистика нигезендә Җылылык картасы булдыру
- таблицалар һәм дашбордлар рәвешендә күзаллау мөмкинлеген көйләү



# ХАЛЫК ИНСПЕКТОРЫ

Система 2014 елның ноябрендә эшли башлады.

Мобиль җайланмалар ярдәмендә

- юл хәрәкәте һәм/яки территорияне төзекләндерү өлкәсендә административ хокук бозу ихтималлыгы турында,
- юл-транспорт һәлакәте турында хәбәр җибәрергә була.

## нәтиҗәләр

- 2022 елда системага 82 меңнән артык белдерү җибәрелгән
- сервисның мобиль кушымтасын күчереп алу очраклары – 180 меңнән артык
- һәр 10 минут саен системада бер гариза хәл ителә









# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕ СОРАШТЫРУЛАР

Интерактив сораштырулар, электрон рәвештә тавыш бирүләр турында мәгълүматлар бастыру, аларны үткәрү өчен билгеләнгән сервис. 2017 елда Ачык хөкүмәт механизмнарын җәелдерү кысаларында эшләтеп җибәрелде, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталының бер өлеше булып тора.

## нәтиҗәләр

- 11 сораштыру үткәрелгән, алар буенча 294 мең тавыш алынган.
- төзекләндерү максатында җәмәгать киңлекләрен һәм ишегалларын сайлау өчен, «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» онлайн-сораштыруы үткәрелгән, анда 207 мең кеше катнашкан.
- электрон сайлау – ТР Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламентына кандидатлар өчен тавыш бирү үткәрелгән.

# МИНЕМ СУБСИДИЯЛӘР (МОИ СУБСИДИИ)

Эшчәнлек төре буенча төрле ведомстволардан туры килә торган оптималь һәм уңайлы ярдәм чараларын алу максатында эшкуарлар өчен цифрлы сервис.

**59**
ярдәм чарасы

**58,5**
мең гариза

**4,8** млрд.сум

## НӘТИҖӘЛӘРЕ

- сервисны социаль ярдәм чаралары платформасы белән интеграллаштыру
- «ГосТех» бердәм цифрлы платформасына чыгару өчен сынау сервисы буларак билгеләү.
- 85% артык – кулланучыларның канәгать калу дәрәҗәсен бәяләү (CSI).
- ведомстволар теләкләренә туры китереп, башкаручының автоматлаштырылган эш урынын өстәмә эшләп бетерү: интерфейска үзгәрешләр кертелде, excel-форматта чыгару мөмкинлеге белән, хисаплылык өстәмә эшләп бетерелде.
- законнардагы үзгәрешләр нигезендә сервиска модернизация үткәрелде.

## ПЛАННАР

- сервисны «ГосТех» бердәм цифрлы платформасына күчерү.
- ТР министрлыклары һәм ведомстволарының әлеге сервис аша субсидияләр бирү вазыйфаларын билгели торган норматив-хокукый документны раслау.
- сервисны Илебезнең бердәм программа тәэминаты реестрында теркәү.
- функциональ заказчыларның яңа таләпләренә туры китереп, сервисны яңарту.
- яңа ярдәм чаралары чыгару.






# МИН ТӨЗИМ ("Я СТРОЮ")

Гражданнар һәм юридик затлар өчен төзелеш өлкәсендәге барлык мәсьәләләрне бер тәрәзә режимында хәл итү платформасы.

Йорт төзү буенча килештерү процессы ике тапкырга диярлек кыскартылды. Әгәр элек бу процесс 162 көнгә сузылып, 12 мөрәҗәгатьне үз эченә алган булса, хәзер – 89 көн һәм 6 мөрәҗәгать.

## НӘТИҖӘЛӘР

- сервисны Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарына җәелдерү.
- «Мин төзим» («Я строю») платформасын 25 000 уникаль кулланучы караган.
- Татарстан Республикасы буенча платформа аша 712 хезмәт күрсәтелгән.
- «Техник план алу» һәм «Төзелешне планлаштыручы» дигән яңа функционал кертү.

## Кызыклы белешмәләр

Документларны дөрес рәсмиләштермәү сәбәпле, гаризаларны кире кагу очраклары 8 тапкырга кимегән.

Хезмәтләрне рәсмиләштерүгә китә торган вакыт 15 тапкырга – 149 сәгатьтән 9,5 сәгатькә кадәр кыскарган.

## ПЛАННАР

